**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

13 март 2023 ел № 10 ш.т. Урыссу б.

210835 «Туймазы ятмасының 1073ТМЗгс1 санлы эксплуатация скважинасының ян баганасын бораулау ысулы белән реконструкцияләүне инженерлык тәэмин итү» «Башнефть Добыча» ҖЧҖ планлаштыру проекты һәм объект территориясен чикләү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга ярашлы, 2022 елның 14 мартындагы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 58-ФЗ санлы Федераль закон белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге «Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу вакытын озайту, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү үзенчәлекләре турында»гы 575 санлы карары белән, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы белән, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 8 февралендәге «Башнефть Добыча»ҖЧҖ объекты территориясен планлаштыру һәм чикләү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында»гы 11 санлы карары белән, 2023 елның 10 мартындагы 210835 «Туймазы ятмасының 1073ТМЗгс1 санлы эксплуатация скважинасының ян баганасын бораулау ысулы белән реконструкцияләүне инженерлык тәэмин итү» «Башнефть Добыча» ҖЧҖ планлаштыру проекты һәм объект территориясен чикләү проекты буенча ачык тыңлауларның 4 санлы протоколын һәм 210835 «Туймазы ятмасының 1073ТМЗгс1 санлы эксплуатация скважинасының ян баганасын бораулау ысулы белән реконструкцияләүне инженерлык тәэмин итү» «Башнефть Добыча» ҖЧҖ планлаштыру проекты һәм объект территориясен чикләү проектын раслау турындагы нәтиҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Дымтамак авыл

җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан 210835 «Туймазы ятмасының 1073ТМЗгс1 санлы эксплуатация скважинасының ян баганасын бораулау ысулы белән реконструкцияләүне инженерлык тәэмин итү» «Башнефть Добыча» ҖЧҖ планлаштыру проекты һәм объект территориясен чикләү проектын расларга.

2. Әлеге карарны түбәндәге электрон адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы – Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә.Шафигуллин